Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

18 номерлы Карар

Шумково авылы 02.08.2023

"Җир салымы турында" 2006 елның 1 декабрендәге 14 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2006 елның 1 декабрендәге 14 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково авылы, Үзәк урамы, 42 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урамы, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт; Әшнәк-Качкалак авылы, Югары урамы, 5 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Башлыгы Л.М. Нәҗмиев